КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 сентябрь г.Казань № 994

2023 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2023 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнарын һәм күләмнәрен;

2023 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга норматив чыгымнарны.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2022 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 20 сентябрь, 889 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 20 сентябрь, 889 нчы карары белән расланган 2022 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга норматив чыгымнарга үзгәреш кертү хакында» 2022 ел, 21 апрель, 381 нче.

2. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 14 сентябрь, 994 нче
карары белән расланды

2023 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнары һәм күләмнәре

| Т/с | Хезмәт күрсәтү исеме | Норматив чыгымнар бер елга бер берәмлеккә сум | Бер елга хезмәт күрсәтүләр күләме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Гражданнарның законлы хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашыруга, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләрен үтәүгә бәйле архив белешмә кәгазьләрен, архив күчермәләрен, архив өземтәләрен, мәгълүмат хатларын бирү | 1 917,26 | 18 000 | үтәлгән рәсми сораулар саны, берәмлек |
| 2. | Архив документларыннан (күчермәләреннән) һәм аларның белешмә эзләү чараларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү | 1 119,27 | 10 000 | уку залында булу саны, берәмлек |

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 14 сентябрь, 994 нче
карары белән расланды

2023 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга норматив чыгымнар

| Т/с | Эш башкару исеме | Норматив чыгымнар, бер елга сум |
|---|---|---|
| 1. | Архивларны архив документлары белән комплектлау | 18 654 422 |
| 2. | Архив документларының сакланышын һәм исәбен тәэмин итү | 38 241 565 |
| 3. | Архив документларының тасвирламасын эшләү, аларның белешмә һәм эзләү чараларын булдыру, архив фондларының составы һәм эчтәлеге турында белешмә характерындагы мәгълүмат бирү басмаларын әзерләү | 9 327 211 |
| 4. | Архив документларындагы дәүләт серен, закон тарафыннан саклана торган башка серләрне тәшкил итә торган мәгълүматларны саклау һәм аларның сер булуын билгеләнгән тәртиптә бетерүне оештыру | 3 730 884 |
| 5. | Архив эшчәнлеге һәм идарәне документлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча консультация ярдәме һәм методик ярдәм күрсәтү | 5 596 327 |
| 6. | Архив документларының белешмә һәм эзләү чараларыннан «ерактан торып» файдалану мөмкинлеген тәэмин итү | 6 529 048 |
| 7. | Архив документлары нигезендә мәгълүмат чараларын, бастырып чыгару һәм күргәзмә проектларын тормышка ашыру | 9 327 211 |

____________________________